ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 366 от « 01 » октября 2019 г.

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә :

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, концлагерь тоткыннары, репрессияләнгәннәрдән кала, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерү;
- «Төньяк» поселогында халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;
- шәһәр урамнарында тротуарлар ясау.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны Мамадыш шәһәренең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.М. Гарипов